Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

**2021 елның 13 декабре** **№ 74**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 2013 елның18 ноябрендәге 201 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы Уставы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021елның 1 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә , Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 2013 елның 18 ноябрендәге 201 номерлы карарына (22.09.2014 ел, № 240; 20.10.2015 № 16; 12.11.2018 ел, № 164; 16.10.2019 ел, № 221; 25.03.2020 ел, № 247; 22.06.2020 ел, № 258 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**9 статьяның 9 пунктындагы 3 абзацына түбәндәге сүзләр өстәргә:**

«, бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районы Башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе Н.А.Вазыйхов